# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Кәкре Елга авыл җирлегенең
Кәкре Елга торак пунктында
2024 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

**10 ноябрь 2021 ел.** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәкре Елга торак пунктында гражданнар җыены

**карар итте:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән гаиләләрдән һәм махсус операциягә җибәрелгән Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтү турында контракт төзегән гражданнар, бер тапкыр түләүне киметергә, аны 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә билгеләргә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Кәкре Елга торак пунктында су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын ремонтлауны оештыру (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм тоту, су сыйфатын анализлау, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру, муниципаль контракт буенча эш өчен түләү) ;
- Кәкре Елга торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын (янгын сүндерү автомобилен тоту, янгын сүндерү автомобиле йөртүчесе хезмәтенә түләү, янгын сүндерү автомобиле өчен запас частьләр сатып алу) тәэмин итү;
- Кәкре Елга т. п. г. Галимов ур. буенча юлларны вак таш белән каплау (сатып алу, ташу, вак таш салу, контракт буенча эш өчен түләү)
- Кәкре Елга торак пунктында торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту( тракторчыга карны механикалаштырылган җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре, муниципаль контракт буенча эшләр өчен түләү) ;
- Кәкре Елга торак пунктында халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү (материаллар сатып алу һәм әзерләү, «Сабантуй " милли бәйрәмен үткәрү өчен трибуналар һәм эскәмияләр урнаштыру ) ;
- Кәкре Елга торак пунктында традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (зиратта куакларны кисү, муниципаль контракт буенча эш өчен түләү);

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын карап тоту, җәйге вакытта Кәкре Елга торак пункты территориясендә үлән чабу (тракторчыга карны механикалаштырылган җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту буенча чит оешмалар хезмәтләре өчен килешү буенча эш өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш салу, контракт буенча эш өчен түләү, чокыр ремонтлау)Какре-Елга торак пунктының Комсомол урамы;

3. Әлеге карарны Кәкре Елга авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://aznakaevo.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кәкре Елга авыл җирлеге башлыгы
Азнакай муниципаль районы

И. М. Мөхәмммәтҗанов